СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с.Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

“24” сентября 2018 г | № 2-35

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Соколка авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 34 номерлы карары, Соколка авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 6-34 номерлы карары, Соколка авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2018 нче елның 17 че сентябрендә кабул ителгән 6-34 номерлы (23.09. 2018 № 2-11, 17.09.2018 № 5-34 редакцисеяләрендә) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2018 нче елның 18 нче ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1.  Ритуаль хезмәтләр күрсәтү һәм күмү урыннарын тотуны оештыру:
- Соколка һәм Грахань авылларының зиратларга киртә салу.
2. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне , су чыгаруны оештыру,  ягулык белән тәэмин итүне оештыру:
- Соколка авылның су белән тәэмин итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау.
3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:
- Кама аръягы Яңа поселогындагы Г. Тукай урамында һәм Соколка авылында Совет урамында җирле әһәмияттэге автомобиль юлларын төзү.

« ӘЙЕ »  « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге башлыгы А.Г. Рахимзяновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе  /А.Г. Рахимзянов/